**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ЯҢА ЧИШМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елның 17 нче августыннан № 29-111

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакындагы» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2019 елның 15 декабрендәге 50-166 номерлы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 апрелендәге 120-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына казначылык хезмәте күрсәтү һәм казначылык түләүләре системасы өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 479-ФЗ номерлы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге Советына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга ярашлы рәвештә

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлегенең 15.11.2019 № 50-166 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлегендә бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 31.05.2021 №10-32; 05.10.2021 №16-58; 29.06.2022 №20-73; 10.03.2023 №26-97 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 3 өлешенең өченче абзацында «төзергә хокуклы» сүзләрен «төзиләр» сүзенә алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 13 статьясындагы 3 өлешенең дүртенче абзацында «төзергә хокуклы» сүзләрен «төзиләр» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация системасында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» на бастырып

чыгарырга: https//pravo. tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация системасында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https/ novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы В. М. Козлов